КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 июль г.Казань № 573

2021 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен әлеге муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен әлеге муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 15 июль, 573 нче
карары белән расланды

2021 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен әлеге муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2021 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен әлеге муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен 2021 елга Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнар юнәлеше – муниципаль берәмлек территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм үткәрүгә бәйле рәвештә, юридик затларга субсидия бирү.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары түбәндәгеләр була:

муниципаль берәмлекнең тормышка ашыру өчен башка бюджетара трансфертлар бирү гамәлгә ашырыла торган күргәзмә чаралары исемлеген раслый торган хокукый акты булу;

муниципаль берәмлектә экспозиция мәйданчыгы булу;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең финанслар белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булу.

6. Муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты арасында төзелә торган Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла, анда түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең мәгънәсе;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык бирү тәртибе, формасы һәм сроклары һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечен үтәү;

Министрлыкның муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга хокукы;

бу Тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, Килешүне өзү тәртибе;

якларның җаваплылыгы.

Килешү Министрлык тарафыннан раслана торган форма нигезендә төзелә.

7. Башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлек бюджетына алу өчен муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты Министрлыкка, билгеләнгән тәртиптә таныкланган түбәндәге документларны теркәп, башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле рәвештә язылган заявка (алга таба – заявка) тапшыра:

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителгән, вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган күргәзмә чаралары исемлеген тормышка ашыру буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган 2021 елга муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турындагы карардан өземтә;

муниципаль берәмлектәге җирле үзидарә органының Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешендә күргәзмә чаралары тематикасының роле, күргәзмә чараларының максатлары һәм бурычлары, күргәзмә чараларының дәрәҗәсе (халыкара, гомумроссия, төбәкара, республика, җирле әһәмияттәге) күрсәтелгән күргәзмә чараларының календарь планын раслый торган муниципаль хокукый акты;

күргәзмә экспозициясенең күргәзмә чараларына багышланган фотоматериаллар, видео- һәм медиаматериаллар (булган очракта) теркәлә торган дизайн-проекты, шулай ук күргәзмә чаралары буенча презентация материаллары;

әлеге күргәзмә чараларында катнашучы оешмаларның саны турында мәгълүматлар;

күргәзмә чараларын үткәрү өчен экспозиция мәйданчыгының мәйданы турында мәгълүматлар.

8. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитетыннан кергән документлар Министрлык тарафыннан аларны теркәүгә алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә карап тикшерелә. Документлар Министрлык тарафыннан кергән көнендә теркәүгә алына.

Бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган (тулы күләмдә тапшырылмаган) яки тапшырылган документлар, алардагы мәгълүматлар бу Тәртиптә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәгән очракта, шулай ук муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган мәгълүмат

дөрес булмаган очракта, Министрлык заявканы кире кага һәм, заявканы кире кагу турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көннән дә соңга калмыйча, кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына хәбәр итә.

Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты, бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, заявканы кире кагу турында хәбәрнамә алган көннән 10 көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан яңадан бирелгән заявкаларны карап тикшерү тәртибе беренче тапкыр бирелгән заявкаларны карап тикшерү тәртибе белән охшаш.

9. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетына Килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә караган территориаль орган счетына күчерелә.

10. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C = S \times 6\,025{,}67 \text{ сум},$$

монда:

S – күргәзмә чараларын үткәрү өчен экспозиция мәйданчыкларының мәйданы;

6 025,67 сум – экспозиция мәйданчыгының 1 кв.метрына чыгымнарның иң чик күләме.

Муниципаль берәмлеккә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме бу Тәртипнең 3 пунктында каралган бюджет ассигнованиеләреннән һәм бюджет йөкләмәләре лимитларыннан арта алмый.

11. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең күрсәткече – муниципаль берәмлек тарафыннан календарь план нигезендә үткәрелә торган күргәзмә чараларында катнашучы оешмалар саны (кимендә 30).

13. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты Министрлыкка электрон рәвештә һәм кәгазь чыганакта Килешүдә каралган срокларда һәм формада башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечен үтәү турында хисап тапшырырга тиеш.

14. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты һәм аның вазыйфаи затлары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

15. 2021 елның 31 декабре хәленә карата муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган һәм 2022 елның 5 апреленә кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән очракта, 2022 елның 15 маена кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{кайтару}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$V_{кайтару} = (C_i \times D) \times 0{,}1,$$

монда:

$C_i$ – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләме;

D – башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты.

16. Башка бюджетара трансфертны (D) кире кайтару коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$D = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең план буенча мәгънәсе.

17. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

18. 2022 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2022 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Министрлык тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

19. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм бүтән максатларда (бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлардан башка) кулланыла алмый.

20. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___